КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 9 октябрь г.Казань № 1279

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибен раслау хакында» 2016 ел, 4 февраль, 61 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибен раслау хакында» 2016 ел, 4 февраль, 61 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 16 апрель, 234 нче; 2016 ел, 23 июнь, 433 нче; 2016 ел, 14 ноябрь, 840 нчы; 2017 ел, 30 декабрь, 1137 нче; 2019 ел, 19 ноябрь, 1049 нчы; 2020 ел, 25 декабрь, 1186 нчы; 2021 ел, 4 ноябрь, 1051 нче; 2022 ел, 29 декабрь, 1441 нче; 2023 ел, 5 июнь, 687 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләр) территорияләрендә алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорияләрен төзү үзенчәлекләре турында» сүзләрен «Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә алга киткән үсеш территорияләрен төзү үзенчәлекләре турында» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы» сүзләрен «вәкаләтле республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән

үстеш территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибендә:

1 пунктта «Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләр) территорияләрендә алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорияләрен төзү үзенчәлекләре турында» сүзләрен «Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә алга киткән үсеш территорияләрен төзү үзенчәлекләре турында» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта:

дүртенче абзацта «социаль-икътисадый» сүзләрен төшереп калдырырга;

уникенче абзацта «социаль-икътисадый» сүзләрен төшереп калдырырга;

унөченче абзацта «социаль-икътисадый» сүзләрен төшереп калдырырга;

35 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«35. Карар утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш биреп кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, комиссия утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып тора.

Комиссия карары шулай ук читтән торып тавыш бирү юлы белән (сораштыру юлы белән) кабул ителергә мөмкин. Читтән торып тавыш бирүне үткәрү тәртибе комиссия карары белән билгеләнә. Читтән торып тавыш бирүне үткәрү юлы белән (сораштыру юлы белән) кабул ителгән комиссия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа комиссия секретаре кул куя һәм аны комиссия рәисе раслый.

Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул утырыш үткәрелгән көннән биш эш көне эчендә комиссия утырышында рәислек итүче тарафыннан раслана. Комиссиянең беркетмәсе, раслаган көннән алып өч эш көне эчендә, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының һәм башкарма комитетның рәсми сайтларында бастырып чыгарыла.»;

әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасында «Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләр) территорияләрендә алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорияләрен төзү үзенчәлекләре турында» сүзләрен «Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә алга киткән үсеш территорияләрен төзү үзенчәлекләре турында» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланганалга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турындагы килешү формасында:

преамбулада «Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләр) территорияләрендә алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорияләрен төзү үзенчәлекләре турында» сүзләрен «Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә алга киткән үсеш территорияләрен төзү үзенчәлекләре турында» сүзләренә алмаштырырга;

3.2 пунктта «социаль-икътисадый» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин